# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯТМАС-ДУСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
# КАРАРЫ

01 август 2022 №18

Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 31.01.2014 ел 3 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 31 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына, Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә таянып карар бирәм:

1. Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 31.01.2014 ел 3 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының кушымта итеп бирелә торган карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карары проектын әзерләү буенча Комиссиягә 2022 елның 10 августыннан 3 сентябрьгә кадәрге чорда экспозиция һәм җыелыш үткәрү юлы белән гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын 3 нче сентябрьгә 16.00 сәгатькә Кукмара районы, Ятмас Дусай авылы,Үзәк урам 73а йорт адресы буенча мәдәният йорты бинасында үткәрергә билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карары проекты экспозициясен һәм аңа мәгълүмати материалларны Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Ятмас Дусай авылы, Үзәк урамы, 73 а йорт адресы буенча 2022 елның 10 августыннан 3 сентябрьгә кадәр Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында үткәрергә;

5. Экспозициягә килүчеләргә экспозиция урнаштыру урыны буенча түбәндәге график буенча консультация үткәрергә: сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә 9.00 сәгатьтән 11.00 гә, 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда.

6. Билгеләргә:

- Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 31.01.2014 ел 3 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карары проекты Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru// веб-адресы буенча 2022 елның 2 августыннан да соңга калмыйча урнаштырыла;

- карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар 2022 елның 3 сентябрьгә кадәр Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 31.01.2014 ел 3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карары проектын әзерләү буенча Комиссиягә Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Ятмас Дусай авылы, Үзәк урамы, 73а йорт адресы буенча, шулай ук гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын уздыру барышында язмача һәм телдән кертә алалар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтындаурнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы Ф.Х.Гарифуллина

СОВЕТ ЯТМАС-ДУСАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯТМАС ДУСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607753155
ИНН 1623001685

Кушымта

Проект

Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы

КАРАР

2022 елның ___________________ №___

Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 гыйнвар 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 гыйнвар 3 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә (Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 34 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 15 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 3 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 13 номерлы, 2022 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Җир кишәрлекләренең хокук ияләре капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы, әгәр мондый тайпылыш капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән бер яки берничә чик параметрларын бер тапкыр күп дигәндә ун процентка үзгәртү максатларында кирәк булса.»;

1.2. 16 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән унбиш эш көне эчендә әзерләнә һәм җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки

гавами тыңлауларда каралырга тиеш. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны мондый рөхсәтне бирү белән кызыксынган физик яки юридик зат түли.»;

1.3. 26 статьяның 7 пунктындагы дүртенче абзацында «ундүрт көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 27 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү максатыннан, төзүче Башкарма комитетка төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза җибәрә. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, гавами сервитут билгеләү турында карар, шулай ук территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләре урнашуның аның нигезендә әлеге җир кишәрлеге төзелгән һәм җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән схемасы, Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта, әгәр Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7.3 өлешендә башкача билгеләнмәгән булса;

Россия Федерациясе бюджет законнарында, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан билгеләнгән очракларда, бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешү булганда – әлеге килешү, әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә хокукын билгели торган документлар;

3) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көнгә кадәр кимендә өч ел элек бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштыру өчен җир кишәрлеге төзү таләп ителми торган линияле объект төзүгә рөхсәт биргән очракта, территорияне планлаштыру проекты реквизитлары;

4) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм расланган проект документларындагы түбәндәге материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеген планлаштыруны оештыру схемасы, ә линияле объектларга карата проект документациясен әзерләү очрагында, территорияне планлаштыру проекты нигезендә эшләнгән бүлеп бирелгән полоса проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен

территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);

в) архитектура һәм конструктив карарлар, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар булган бүлекләр (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документациясен әзерләү очрагында);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү капиталь төзелешнең башка объектларын төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булган очракта, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү буенча эшләрне оештыру проектын да кертеп);

5) аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләре башкарыла торган проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе (проект документларының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе өлешендә), шул исәптән, әлеге проект документациясе белән, линияле объектларны да кертеп (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 48 статьясындагы 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), башка капиталь төзелеш объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган очракта, әгәр мондый проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза үткәрелергә тиеш булса, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

6) проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән үзкөйләнешле оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән, проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә үзгәрешләр кертелгән очракта, һәм әлеге зат тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җәлеп ителгән проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган, проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;

7) проект документларына экспертиза үткәргән башкарма хакимият органы яисә оешма тарафыннан бирелгән, проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау,

проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә эксперт ярдәме барышында үзгәрешләр кертелгән очракта;

8) рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт ((әгәр төзүчегә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы нигезендә мондый рөхсәт бирелгән очракта);

9) мондый объектны үзгәртеп корган очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, әлеге пунктның 11 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортны үзгәртеп кору очракларыннан тыш, блоклы төзелештәге бер йортны үзгәртеп кору очрагында, блоклы төзелештәге бер рәттәге барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы;

10) Дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы булып торучы дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яисә күрсәтелгән орган гамәлгә куючы яисә мөлкәт хуҗасы хокукының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган автоном учреждениесе хокукындагы дәүләт (муниципаль) милке булган капиталь төзелеш объектында реконструкция үткәрелгән очракта, – мондый реконструкцияләүне уздыру турында, шул исәптән реконструкцияне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгели торган килешү;

11) күпфатирлы йортта биналарның һәм машина-урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышының күпфатирлы йортны үзгәртеп корганда торак законнары нигезендә кабул ителгән карары яки, мондый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми милек күләме киметелгән очракта, күпфатирлы йортта биналарның һәм машина-урыннарның барлык милекчеләренең ризалыгы;

12) проект документларына дәүләти булмаган экспертиза бәяләмәсе тапшырылган очракта, проект документларына дәүләти булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затны аккредитацияләү турында таныклыкның күчермәсе;

13) мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкарганда, мондый объектның конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлыгының башка характеристикаларына кагылса, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнары белән каралган документлар;

14) капиталь төзелеш объекты төзелгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә, аны урнаштыру белән бәйле рәвештә, территориядән файдалануның аерым шартлары булган зона билгеләнергә тиешле яисә капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корганда, аның нәтиҗәсендә үзгәртеп корылган объектка карата территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле яисә элек махсус шартлар тудырылган үзгәртелергә тиешле территорияне махсус шартлар белән куллануның зонасын билгеләү яки үзгәртү, аны урнаштыру белән бәйле рәвештә,

капиталь төзелеш объекты төзелгән очракта, территорияне махсус шартлар булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар күчермәсе;

15) капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүне җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта, территорияне үстерү турында шартнамә күчермәсе (Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы яисә муниципаль берәмлек тарафыннан территорияләрне комплекслы үстерү турында карарны мөстәкыйль рәвештә яки яисә Россия Федерациясе яисә мондый карарны Татарстан Республикасы тарафыннан билгеләнгән юридик зат тарафыннан гамәлгә ашыру очракларыннан тыш).»;

б) 9 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелеш этабы дигәндә бер җир кишәрлегендә төзелергә, реконструкцияләнергә планлаштырылган капиталь төзелеш объектлары арасыннан капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү, әгәр мондый объект файдалануга тапшырылырга һәм автоном рәвештә (ягъни, бу җир кишәрлегендә башка капиталь төзелеш объектларын төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә) эксплуатацияләнергә мөмкин булса, капиталь төзелеш объектының бер өлешен (ягъни, бу капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә) төзү яки реконструкцияләү, шулай ук капиталь төзелеш объектын (капиталь төзелеш объектының бер өлешен) урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләренә ия булу һәм алардан файдалану хокукларын рәсмиләштерүне үз эченә алган төзелеш территориясен әзерләү буенча эшләр комплексы, биналарны, корылмаларны һәм каралтыларны сүтү, инженерлык коммуникацияләрен үзгәртеп кору (күчерү), вакытлыча биналар һәм корылмалар төзү, урман кисү һәм башка эшләр күздә тотыла. Җитештерү өчен билгеләнгән объектларга карата да төзелеш этабы дигәндә территорияне планлаштыру, төзекләндерү, яшелләндерү һәм яктырту буенча эшләр комплексы күздә тотыла.»

1.5. 28 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Капиталь төзелеш объектының, кирәклеге мондый объектны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау барышында ачыкланган параметрларын проект документларыннан тайпылдыру бары тик төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы файдалану өчен җаваплы зат яисә төбәк операторы тарафыннан бары тик яңадан расланган проект документлары нигезендә генә, аңа Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тиешле үзгәрешләр керткәннән соң гына рөхсәт ителә».

б) 10 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән объектларга карата гамәлгә ашырыла. Дәүләт төзелешен күзәтү предметы булып түбәндәгеләр тора: капиталь төзелеш объектын төзү,

үзгәртеп кору процессында башкарыла торган эшләрнең һәм кулланыла торган төзелеш материалларының һәм эшләнмәләрнең, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләренең расланган проект документациясе (шул исәптән, эш документларына кертелгән һәм мондый проект документларының бер өлеше булган үзгәрешләрне исәпкә алып) таләпләренә һәм (яисә) и (или) мәгълүмати модельгә мәгълүмати модельне формалаштыру һәм алып бару Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китереп мәҗбүри булган очракта) туры килүе; төзелешкә рөхсәт булу таләпләре; Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 2 һәм 3.1 өлешләрендә билгеләнгән таләпләр; капиталь төзелеш объектын консервацияләүне тәэмин итүгә карата Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән таләпләр; төзелеш контролен гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр.»»

1.6. 29 статьяда:

а) 3 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) капиталь төзелеш объектының проект документларының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документларының таләпләренә (шул исәптән эш документларына кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 1.3 өлеше нигезендә мондый проект документларының бер өлеше булып торган үзгәрешләрне исәпкә алып) туры килү-килмәве турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе (дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган очракта), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган башкарма хакимиятнең федераль органының (алга таба - федераль дәүләт экология күзәтчелеге органы) федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вәкил бәяләмәсе;

б) 4 пунктта «ун көн эчендә» сүзләрен «биш эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру рөхсәтенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән документларның булмавы;

2) капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәт алу өчен бирелгән тәкъдим ителгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә, яки линияле объектны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштыру өчен җир кишәрлеге төзү таләп ителми торган линияле объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирелгән очракта,

территорияне планлаштыру проекты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

3) капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданы әлеге статьяның 5.2 пункты нигезендә үзгәртелгән очраклардан тыш;

4) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объекты параметрларының проект документларына туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын әлеге статьяның 5.1 пункты нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш;

5) капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт ителгән файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирелгән көнгә билгеләнгән чикләүләргә туры килмәве, әгәр күрсәтелгән чикләүләр территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешенең 9 пунктында каралган очракларда кабул ителгән карарда каралган һәм аның урнашуына бәйле рәвештә территорияне файдалануның махсус шартлары булган зона урнаштырылган яки үзгәртелгән төзелә, реконструкцияләнә торган капиталь төзелеш объекты, файдалануга кертелмәгән очраклардан тыш.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 5.1 пунктын өстәргә:

«5.1. Капиталь төзелеш объектының техник планда күрсәтелгән мәйданының линияле объект булмаган мәйданы турындагы белешмәләрнең проект документларында һәм (яки) төзелешкә рөхсәтнамәдә күрсәтелгән мәгълүматларга карата биш проценттан да артмаган аермасы техник планда күрсәтелгән катлар, биналар (булган очракта) һәм машинаурыннар санының (булган очракта) һәм проект документациясе һәм (яки) төзелешкә рөхсәт файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. линияле объектның техник планда күрсәтелгән озынлыгы турында мәгълүматларның аның проект документларында һәм (яки) төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән озынлыгы турындагы мәгълүматларга карата биш проценттан да артмаган булуы объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

1.7. 30 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр проектын әзерләү турындагы карар Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карар рәвешендә кабул ителә.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карау өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең җирлекнең генераль планына, муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасына мондый генераль планнарга яки муниципаль районның территориаль

планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә барлыкка килгән туры килмәве;

2) территориаль зоналар чикләрен үзгәртү, шәһәр төзелеше регламентларын үзгәртү турында тәкъдимнәр керү;

3) шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында күрсәтелгән территорияләрне, мәдәни мирас объектлары территорияләрен куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең урнашу урыны турында белешмәләрнең Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы күрсәтелгән зоналарның, территорияләрнең урнашу урыннары тасвирламасына туры килмәве;

4) шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән тулысынча яисә өлешчә территорияләрне файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә, федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге истәлекле урыннар территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүнең Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булган мондый зоналар, территорияләр чикләрендә күчемсез милек объектларын куллану чикләренә туры килмәве;

5) территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаның яшәешен билгеләү, үзгәртү, туктату, мәдәни мирас объекты территориясенең, федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе, төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен билгеләү, үзгәртү;

6) территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү;

7) Ватанны саклаганда һәлак булган кешеләрнең муниципаль берәмлекләр чикләрендә урнашкан күмелгән урыннарын табу.»;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр җибәрелә:

1) федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан, әлеге Кагыйдәләр федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан, әлеге Кагыйдәләр төбәк әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда;

3) Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан, әлеге Кагыйдәләр җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда;

4) җирле үзидарә органнары тарафыннан, әгәр Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруны җайга салу тәртибен камилләштерергә кирәк булса;

5) җирле үзидарә органнары тарафыннан, Ватанны саклаганда һәлак булган кешеләрнең Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан күмелгән урыннарын табу очракларында;

6) физик яки юридик затлар тарафыннан инициатив тәртиптә йә әлеге җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын куллану нәтиҗәле булмаса, аларның хокук ияләренә зыян килсә, җир кишәрлекләренең һәм

капиталь төзелеш объектларының хакы кимесә, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре гамәлгә ашырылмый торган очракларда;

6) башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы тарафыннан яки Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат тарафыннан;

7) Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән һәм Татарстан Республикасы тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат, территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат тарафыннан.»;

в) 6 пунктта «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга;

г) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә конкрет территориаль зона өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентына үзгәрешләр кертү өлешендә үзгәрешләр әзерләү очрагында, шулай ук территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр әзерләү очрагында, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар мондый шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территориаль зона чикләрендә, комплекслы үстерүгә тиешле территория чикләрендә үткәрелә. Бу очракларда иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар үткәрү вакыты бер айдан да артык була алмый.»;

18. 32 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.Территориаль зоналарның чикләре һәр җир кишәрлегенең бер генә территориаль зонага карау таләбенә туры килергә тиеш, җир законнары нигезендә территориаль зоналар чикләрен кисәргә мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Ф.Х.Гапифуллина